**Республика Татарстан**

**Ютазинский**

**муниципальный район**

**Палата имущественных и земельных отношений**

**423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, 38**

**тел./факс (85593) 2-42-19**

**Татарстан Республикасы**
**Ютазы муниципаль районы**

**Җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы**

**423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38**

**тел./факс (85593) 2-42-19**

---

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

№ 1 от « 27 » 03 2025 г.

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының «Ютазы муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияне үтәвенең административ регламентын раслау турында»гы 17.05.2017 ел, № 2 санлы күрсәтмәсенең үз көчен югалтуын тану хакында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»гы 31.07.2020 ел, № 248-ФЗ санлы Федераль законның һәм Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 29.10.2021 ел, № 81 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында нигезләмәнең үз көченә керүенә бәйле рәвештә, к а р а р б и р ә м:

1. Ютазы муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының "Ютазы муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияне үтәвенең административ регламентын раслау турында"гы 17.05.2017 ел, № 2 санлы күрсәтмәсен үз көчен югалткан дип таныргa.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан

Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Ютазы муниципаль районының
Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре
палатасы рәисе А.М. Хөббатова